Республика Татарстан
Александровское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Александровка
авыл җирлеге

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26нче август 2024 ел** **№16**

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гараж берләшмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 пункты, Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 21 декабрендәге 15номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 нче кушымтаның 11 пунктында “, яисә физик затларның гомерлек мирас итеп биләгән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануында, әгәр мондый җир кишәрлеге әлеге Кодексны гамәлгә кертү көненә кадәр бирелгән булса һәм шул ук вакытта мондый җир кишәрлеге хосусый милектә була алмый икән“, сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф.Вафин